| | | |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**БОЕРЫГЫ** |
| 12.07.2025 | | № 288 |

**Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб составына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб төзү турында» 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 апрелендәге 150 номерлы, 2022 елның 6 июлендәге 226 номерлы, 2022 елның 9 сентябрендәге 294 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге 416 номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 13 маендагы 166 номерлы һәм 2025 елның 5 апрелендәге 147 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб (алга таба – Оператив штаб) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Оператив штаб составыннан Э.И. Гафуровны, Е.И. Григорьеваны, М.М. Миңнуллинны, П.М. Олейникны чыгарырга;

Оператив штаб составына кертергә:

Абашев Альмир Рәшит улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасарын;

Григорьев Михаил Александровичны – Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Дәлкарнәев Марсель Сарыйм улын – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Нәбиуллин Рафил Рафикъ улын – Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгының хәрби-сәяси (сәяси) эш буенча урынбасары – Идарәнең хәрби-сәяси (сәяси) эш бүлекчәсе башлыгын (килешү буенча).

**Татарстан Республикасы Рәисе** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ